ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«29» 12 2025 ел** **№330**

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Балтач муниципаль районында яшәүчеләрнең «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү турындагы мәсьәләне хәл итүдә катнашу хокукларын саклау максатларында гавами тыңлаулар уздырып, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләре турында» 2025 елның 17 декабрендәге 28 номерлы карарында чагылдырылган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чикләренә туры китерү мәсьәләсе буенча инициативаны карау турында гавами тыңлаулар үткәрергә.

2. Әлеге карарны 2025 елның 29 декабренә кадәрге вакыт эчендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Татарстан Республикасы, Балтач шәһәр тибындагы поселогы, Ленин урамы, 42 йорт адресы буенча урнашкан административ бинаның утырышлар залын (3 кат) гавами тыңлаулар уздыру урыны дип билгеләргә, үткәрү вакыты 2026 елның 29 январенда, 14 сәгать 00 минутта.

4. Фикер алышу мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр, искәрмәләр кертү һәм чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: Татарстан Республикасы, Балтач шәһәр тибындагы поселогы, Ленин урамы, 42 йорт, Татарстан Республикасы Балтач район Советының оештыру бүлеге (3 кат), эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

5. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар

тапшыру вакыты - 2026 елның 28 январена кадәр.

6. Татарстан Республикасы Балтач район Советының оештыру бүлегенә Татарстан Республикасы Балтач район Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 19 мартындагы 242 номерлы карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2025 елның 17 декабрендәге 28 номерлы карарында чагылдырылган инициативаны карау буенча әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач
муниципаль район Башлыгы Р.Р.Нотфуллин